Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№34 (85)

31 октябрь 2013 ел



# Татар теле рекорд куйды

Казан университеты һәрдаим үзендә кунаклар кабул итә, студентларга укыр өчен яхшы шартлар булдыру өстендә эшли. Университетның эшчәнлеген, аның дөньяга танылуын кемнәр тәэмин итә? Әлбәттә, студентлар! Шуңа күрә лаеклы яшь буынны җәлеп итү өчен, университетта төрле чаралар уза. *Дәвамы 2 биттә .*

## • Вакыйгалар эзеннән

КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты аспиранты **АРСЕНИЙ МОРОВ** (фәнни җитәкчесе – Р.М.Сабиров) Япония хакимиятенең **«MONBUKAGAKUSHO: MEXT» ГРАНТЫН ОТТЫ**. Ул моңа түбән хордалы хайваннар эволюциясенең молекуляр механизмнарын өйрәнеп лаек булды.

• • • •

**25-26 ОКТЯБРЬ КӨННӘРЕНДӘ УНИВЕРСИТЕТТА ДЕБАТЛАР БУЕНЧА ТУРНИР УЗДЫРЫЛДЫ**. Фикерләренең хаклыгына барлыгы 16 команда ышандырырга тырышты. Нәтиҗәдә дүртенче урынга «Ego» командасы лаек булды, өченче урын исә «Вместе» командасыныкы (ике команда да Халыкара багланышлар институтыннан). Икенче урынны фәлсәфә факультетының «Канцлер Бисмарк» командасы яулады. Җиңүче исеменә бер кешедән торган «Казахстан» моно-командасы – фәлсәфә факультеты студенты Елизавета Платонова лаек дип табылды.

• • • •

**28 ОКТЯБРЬДӘ** Казанның Ж.А.Зайцева ис. **122 НОМЕРЛЫ ГИМНАЗИЯСЕНДӘ ФӘННИ-МЕТОДОЛОГИК СЕМИНАР УЗДЫ**. Анда Филология һәм сәнгать институтының рус һәм чит ил филологиясе бүлеге һәм татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге профессорлары, укытучылары һәм студентлары да катнашты. Чараның максаты – гимназия белән булган хезмәттәшлекне ныгыту, укучыларны университетыбыз белән таныштыру һәм потенциаль абитуриентлар туплау.

• • • •

29 октябрь көнне ТР Журналистлар союзының иркен конференц-залында **«АРТ СТИЛЕНДӘГЕ ЧЕЛТӘРЛЕ ЖУРНАЛИСТИКА: ПРОБЛЕМА ҺӘМ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ»** дип исемләнгән Халыкара вузара фәнни-гамәли конференция булды. Әлеге чара КФУның электрон гаммәви чаралары теориясе һәм практикасы кафедрасы һәм Н.Г.Җиһанов ис. Казан дәүләт консерваториясенең музыкаль-гамәли технологияләр кафедрасының уртак проекты булып тора.

• • • •

**29 ОКТЯБРЬ** көнне **КФУ**ның **IT-ЛИЦЕЕНДА ТР ПРОКУРОРЫ И.НАФИКОВ БЕЛӘН ОЧРАШУ БУЛДЫ**. Аның белән бергә, предпринимательләр хокукын саклау буенча надзор бүлеге прокуроры Т.Гыйльманов, укуукыту эшләре буенча проректор Р.Минзарипов һәм ректор киңәшчесе, Вузга кадәрле, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры Л.Ногманова лар да килде. Визит кысаларында лицейның 9 сыйныф укучылары белән түгәрәк өстәл оештырылды. Анда хокук һәм мораль, уйлап табулар өчен җаваплылык мәсьәләләре турында сөйләштеләр.

• • • •

Кичә Казан университетының Тарих музеенда сәяси репрессияләрдә корбан булганнар истәлегенә багышлап **«СТАЛИН ШАЛЯПИНГА КАРШЫ. БӨЕК ҖЫРЧЫ ҮЛЕМЕНЕҢ СЕРЕ** (автор тикшерүләре)» исемле лекция булды. Аны контрразведка органнары ветераны Р.А.Кашапов алып барды.

• • • •

30 октябрьдә КФУның Экология һәм география институты TSI компаниясе (АКШ) белән берлектә **«ТЕХНОЛОГИИ ИССЛЕДОВАНИЯ АЭРОЗОЛЬНЫХ ЧАСТИЦ В НАНОМЕТРОВОМ И МИКРОННОМ ДИАПАЗОНЕ РАЗМЕРОВ»** исемле уртак фәнни семинар үткәрде. Анда TSI компаниясенең аэрозольләрне контрольдә тоту буенча бүлек җитәкчесе Томас Кринке да катнашты.

• • • •

Шул ук көнне Казан университетына Халыкара белем бирү буенча **АМЕРИКА СОВЕТЛАРЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Анда КФУ җитәкчелеге Халыкара белем бирү буенча Америка советлары президенты Дэн Дэвидсон, әлеге советның программа директоры (Вице-Президент) Анн Доморад, Россиядә Халыкара белем бирү буенча Америка советларының директоры Картер Джонсоннар белән очрашты.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

**• Уртак җиң**

# Алда зур эшләр көтә



Казан федераль университеты дөнья күләмендә билгеле булган фәнни-мәгариф үзәкләре арасында РФнең алдынгы университетларында конкурентлыкка сәләтлелекне арттыру Советы (Халыкара Совет) тарафыннан расланган уку йортлары исемлегенә керде.

Динә МӨХТӘСИПОВА

Бу турыда РФ Мәгариф һәм фән министры Дмитрий Ливанов хәбәр итте. Дөньякүләм мәгариф рейтинглары исемлегенә эләгү өчен уздырылган сайлап алуда университетларның «Юл карталары» тәкъдир ителде. Шул исемлеккә эләккәннәр дәүләт тарафыннан финансланачак.

25-26 октябрь көннәрендә **Д.Ливанов** җитәкчелегендә узган Халыкара Совет утырышында 15 университетның «Юл карталары» каралды. КФУны ректор **Илшат Гафуров** җитәкчелегендәге делегация тәкъдир итте. Анда кайбер проректорлар һәм институт директорлары катнашты.

Үз чыгышында И.Гафуров әлеге зур масштаблы эштә, уку йортының 2020 елга кадәр үсеш стратегиясен төзүдә, барлык төп структур бүлекләрнең катнашуын әйтте. «Башта һәркайсы үз «юл картасы»н әзерләде. Ул үз потенциалларын исәпкә алып һәм шул өлкә буенча ил күләмендә билгеле трендларны анализлап әзерләнде. Алга таба бу планнар безнең коллектив, тышкы консультантлар алдында якланды. Университетның «юл картасы» – ул, фактик яктан караганда, структур бүлекләрнең киләчәккә планнар җыелмасы»,– диде.

**Төп күрсәткечләрне тормышка ашырганда, Казан федераль университеты 2020 елга:**

- 50дән артык даими мегагрантлар булдыру (дөнья күләмендә билгеле галимнәр);
- югары классны 100 чакырылган тикшеренүчене чакыру;
- постдокның (докторлык дәрәҗәсе алган галим тарафыннан башкарыла торган фәнни-тикшеренү эше) 150 ияа позициясе;
- scopus һәм WoS базаларында бер елга 5 мең мәкалә бастыру;
- укытучыларның 50 процентына чит илдә эшләү тәҗрибәсе туплау мөмкинлеге бирү;
- дөнья күләмендә билгеле булырлык 100 тикшеренү лабораториясе ачу;
- чит ил партнерлары белән берлектә 250 төрле белем бирү программалары эшләү;
- чит ил студентларының санын 15 процентка җиткерүне планлаштыра.

Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм халыкара Совет вузларның эшчәнлеге буенча даими рәвештә мониторинг уздырып торачак. Бәяләмә биргәндә, чит ил студентлары санынынан алып, яңа белем бирү эшләнмәләренә кадәр исәпкә алыначак. Д.Ливанов: «Рейтингларга эләгү үзмаксат түгел, бу хәтта проектның төп нәтиҗәсе дә булып тормый. Без, беренче чиратта, белем бирү һәм тикшеренү эшләренең сыйфатын яңа дәрәҗәгә күтәререгә тиеш», – диде. Шуны да әйтергә кирәк: бөтен уку йортлары да сайлау турын үтә алмады. Санкт-Петербург дәүләт электротехник университетына, Королев ис. Самара аэрокосмик институтына, Ерак Көнчыгыш федераль университетына презентацияләрен тулыландырырга кушылды. Алар март аенда тагын бер мәртәбә сынау аша узачак.

*Матбугат үзәге материаллары файдаланылды*

**• Белем баскычлары**

# Татар теле рекорд куйды

Яңа уку елын башлап, беренче курсларны әле «багышлап» та өлгермәгән килеш, университетыбызның кабул итү комиссиясе инде, җиң сызганып, үзенә абитуриентлар туплау белән шөгыльләнә башлады.

Алинә САДЫЙКОВА

Һәр көн диярлек (кайбер көннәрдә хәтта берничә тапкыр да булырга мөмкин) кабул итү комиссиясе мәктәп укучылары өчен Казан федераль университеты турында мәгълүмат бирә торган презентацияләр күрсәтә. Мисал өчен, 30 октябрь көнне Башкортстанның Янаул районыннан 10-11 сыйныф укучылары делегациясе килде. Чит республика вәкилләре булганлыктан, кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **Сергей Ионенко** аларга Казан шәһәренең данлыклы, матур һәм тарихи урыннары турында зур булмаган видеоязма күрсәтте. Башкалабыз турында беркадәр күзаллау барлыкка китергәннән соң, аның тагын бер уникаль объекты – Университетның бар ... 

Университетның уникаль объекты – Универсиада авылы турында тәкъдир итте. Башкортстан кунаклары андагы заманча итеп эшләнгән бүлмәләрне, студентлар өчен тудырылган уңайлыкларны күрә һәм бәяли алдылар.

Кызыклы видеоязмалар белән укучыларның игътибарын җәлеп иткәннән соң, С.Ионенко Казан федераль университетының структурасын, асылын билгели торган презентация күрсәтте. Иң элек, ул федераль университетның статусы, аның дәрәҗәсе һәм әлеге бренд тәкъдим итә ала торган мөмкинлекләр турында әйтеп узды. Уку йорты турында гомуми мәгълүмат биргәч, С.Ионенко һәр институтка тукталып, алар турында тулырак сөйләде. Документларны электрон рәвештә кабул итү мөмкинлеге чит республика вәкилләрендә аеруча кызыксыну уятты. Алар аны бик уңайлы һәм функциональ дип тапты. Һәр җөмләне игътибар белән тыңлап утырган укучылар, С.Ионенконың чыгышыннан соң, кызыксындырган сорауларын бирделәр. «Мәктәп укучылары белән мондый форматтагы чаралар инде берничә ел рәттән уздырыла. Соңгы елларда визитларның саны арта бара. Бу Россиянең төрле шәһәрләрендә уздырыла торган белем бирү күргәзмәләрендә актив катнашуыбыз нәтиҗәседер», – дип билгеләп үтте С.Ионенко.

Мондый төр презентацияләр сентябрьдән башланып, апрель аена кадәр дәвам итә. Аның географиясе дә киң: бөтен Идел буе округы. Казан университеты белән кызыксынган мәктәпләр үзләре алдан кабул итү комиссиясе белән элемтәгә кереп, очрашу турында сөйләшәләр һәм билгеләнгән көнгә 30-40 укучыдан торган төркем белән безгә кунакка киләләр.

Гомумән, кабул итү комиссиясе укучылар белән төрле яклап эшли, һәрдаим элемтәдә тора. Моның өчен чит төбәкләрдән килгән студент-волонтерлар күпләп җәлеп ителә. Алар үз якларында, үзләре укыган мәктәптә КФУ турында сөйлиләр, буклетлар тараталар һәм шул рәвешле агитацион эш башкаралар.

Укучыларны җәлеп итә торган тагын бер фактор – Казан университеты үткәрә торган интернет-олимпиада. Масштабы ягыннан ул Россиядә иң зурлардан санала. Быел анда 24 меңнән артык укучы катнашкан. Татар теле буенча олимпиадада катнашучылар саны быел рекорд куйды. Алар – 3 меңгә якын.

Кабул итү комиссиясенең эше абитуриентлар туплау белән генә тәмамланмый әле. Билгеле булганча, быел Казан университеты структурасына Н.И.Лобачевский исемендәге лицей кушылды. «Без лицей укучыларына БДИга әзерләнү өчен дәресләклләр төзибез. Рус теле һәм рус әдәбиятыннан алар инде әзер. Тиздән җәмгыять белеме, тарих, инглиз теле, математика буенча китаплар чыгачак», – диде С.Ионенко тагын бер эшчәнлекләре турында. Монда иң мөһим фактор шул: әлеге дәресләкләрне БДИ буенча предмет комиссиясе рәисләре әзерли. Алар бу эшне имтиханнарны биремнәрне, узган елларда ясалган хаталарны истә тотып башкаралар.

**• Галәм киңлекләре**

Фән дөньясы гаммәви мәгълүмат чараларында ни рәвешле яктыртыла? Әлеге сорауга җавапны без Р.П.Бакановның «Хәзерге фән һәм журналистиканың актуаль мәсьәләләре» лекцияләрендә эзлибез. 29 октябрь көнне без әлеге курс кысаларында гади студентлардан үзенчәлекле фәнни пресс-конференциягә катнашучыларга әверелдек. Безгә кунакка КФУның Физика институтыннан астрономия кафедрасының өлкән фәнни хезмәткәре, доцент, физика-математика фәннәре кандидаты Алмаз Галиев килде.

# Казан университеты дигән планета бар!



Ләйсән ИСХАКОВА, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

**Алмаз Илсур улы Галиев** үзе дә кайчандыр безнең кебек студент булган кеше. Ул КДУның физика факультеты, астрономия кафедрасында укыган. Шуңа да очрашуның төп өлеше астрономия фәненең гаммәви мәгълүмат чараларында яктыртылуы хакындагы мәсьәләләргә бәйле булды. Ул журналистларның метеор белән метеоритны, планеталар белән йолдызларны бутау очракларына мисаллар китерде. Баксаң, бу төшенчәләр мәгънә ягыннан бөтенләй төрле һәм аларны бутап әйтү, язу мәгънәви хатага китерә. Гадәттә, күбебез иң якты йолдыз дигәндә, поляр йолдызны атый. Әмма бу да дөреслеккә туры килми икән. Галәмдәге иң якты йолдыз – ул Сириус. Астрономия һәм астрологияне бутау да шактый киң таралган хата икән. А.Галиев: «Астрономны астролог дип атау – аны мыскыл итүгә тиң», – дигән фикер җиткерде.

Фән турында журналистик материал иҗат иткәндә, мәгънәви яктан аңлашылмаучанлыклар, фәнни яктан төгәлсезлекләр китмәсен өчен, А.Галиев безгә мәгълүматны кабат-кабат тикшерергә, моңа вакытны кызганмаска киңәш итте. Ник дигәндә, язмалардагы төгәлсезлек яки ялган фактлар китерү журналистның гына түгел, ә мәгълүмат биргән галим, фәнни хезмәткәрләрнең дә дәрәҗәсен төшерә. Шул сәбәпле бу өлкәдә эшләүче күп кенә белгечләр журналистлар белән элемтәгә керергә атлыгып тормый. Очрашу кунагы язманың исеме генә түгел, ә эчтәлеге дә тулы һәм аңлаешлы булырга тиеш, дигән фикердә тора.

Астрономия өлкәсендәге яңалыклар бүгенге матбугатта шактый киң яктыртыла. Бу бигрәк тә февраль аенда Чиләбегә метеорит төшкәннән соң ачык күренде. Сүз уңаеннан, метеоритның кайдадыр тайгага төшмичә, нәкъ менә шәһәргә төшүен А.Галиев уникаль күренеш дип атады. Чөнки күпләр аны үз күзләре белән күрделәр һәм галәм киңлекләрендә башка объектларның чыннан да булуына ышандылар. Аның зурлыгы ягыннан чагыштырмача кечкенә булуы гына Чиләбе һәм аның тирәсендәге авыл-салаларны зур масштаблы фаҗигадән йолып калды.

Хәзерге заманда йолдыз сату, йолдызларга исем бирү белән шөгыльләнә торган махсус фирмалар бар. Әмма, Алмаз әфәнде фикеренчә, мондый фирмалар хезмәтеннән файдаланучылар акчаларын җилгә генә очырачак. Чөнки йолдызларга исемне бары тик Халыкара космик Союз гына бирә ала. Йөзләгән йолдызлар үз атамаларын инде борынгы заманнарда ук алган. Кайбер йолдызлар үзләрен өйрәнгән яки ачкан галим исемнәре белән аталган. Планеталарга атаманы да аны ачкан галимнәр биргән. Иң элек планеталарга хатын-кыз исемнәре кушылган. Алар беткәч, географик атамаларга (Мәскәү, Казан дигән планеталар бар – авт.), күренекле кешеләр исемнәренә (Высоцкий, Есенин) күчкәннәр. Әмма искәрмәләр дә юк түгел: планеталар, гадәттә, сәясәтче һәм хәрби чиндагы кешеләр исеме белән аталмыйлар икән. Чөнки Астрономик Союз атамаларда бернинди сәяси мотивлар булырга тиеш түгел, дип билгеләгән. 2004 елда галәм киңлекләрендәге бер кече планетага официаль рәвештә Казан университеты исеме бирелгән. Бүген ул KAZAN UNIVERSITY атамасын йөртә. Димәк, университетыбызның галәмдә дә үз планетасы бар!

Галимнәребез

# Галим, педагог һәм гражданин

**Гөлшат МОСТАФИНА**,
тарихи белем бирү кафедрасы доценты

30 октябрь көнне ярты гасырга якын Казан дәүләт педагогика институтында хезмәт куйган, танылган галим-тарихчы, педагог Рифгат Шакирҗан улы Таһировның (1903-1973) тууына 110 ел булды.





Р.Таһиров (уртада) бертуганнары Әхмәт-Солтан һәм Фаик белән. *1936 ел*

Ул XIX гасыр ахыры, XX гасыр башларында танылган педагог-мәгърифәтче, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр авторы, Казан татар укытучылар мәктәбе мөгаллиме Шакирҗан Таһири гаиләсендә туа. Әлеге гаилә вәкилләренең күпчелеге укытучылык һөнәрен сайлый. Алар арасында татар хатын-кызларына белем бирү өлкәсендә танылган Суфия һәм Зөһрә Таһировалар да бар. Олы уллары Әхмәт-Солтан Мөселман халыклары комиссариаты әгъзасы булуы, Идел-Урал штатын төзү хәрәкәтендә катнашуы белән тарихка кереп калган. Кече малайлары Фаик – танылган рәссам-график.

Р.Таһировның яшьлеге, уку дәвере һәм һөнәри яктан үзбилгеләнүе Совет чорының беренче елларына туры килә һәм ул, бар күңелен биреп, мәгърифәтчелек, фәнни-тикшеренү, җәмәгать эшләренә кереп китә. 1923 елда, Казан университетының рабфагын тәмамлаганнан соң, Көнчыгыш-педагогика институтының Көнчыгышны өйрәнү бүлегенә укырга керә.

Студент вакытларында ук фәнни-тикшеренү эшләре белән кызыксына башлый, 1920 елларда библиография һәм китапханә эше өлкәсендә танылган белгеч була. 1925 елда ТАССР Китап палатасын оештыру инициативасы белән яна. Аның тәкъдиме хуплана һәм бер елдан соң гамәлгә ашырыла. Шул ук елларда Р.Таһиров туган якны өйрәнү белән кызыксына башлый һәм җирле төбәкнең тарихына багышланган хезмәтләр бастыра. 1920 елларда мәктәп мәгарифе системасында экскурсияләр оештыруга зур игътибар бирелгән. Әлеге эшне башкару өчен, ТАССР Наркомпросы экскурсион база булдыра һәм аның рәисе итеп танылган методист, профессор С.П.Сингалевич билгеләнә. 1927 елда аның җитәкчелегендә Р.Таһировның «Экскурсион өйрәтү тәҗрибәсендә татар Казаны» китабы чыга. 1929 елда, инде укытучылык эше белән шөгыльләнә башлагач, «Татар Казанын экскурсион өйрәнүдә методик шартлар» китабын бастыра. Җирле төбәк тарихына багышланган басмалары арасында – «Тарихчы-марксист Г.Ибраһимов», «1917 елда Татарстанда крестьяннар хәрәкәте», күренекле татар революционерлары һәм җәмәгать эшлеклеләре: Х.Ямашев, Г.Колахмәтов, Г.Сәйфетдинов; татарларның 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1912 елгы Ленск забастовкасында катнашу турындагы архив материалларына таянып язылган мәкаләләр.

1928-30 елларда Р.Таһиров Татарстанны өйрәнү җәмгыятенең фәнни сәркатибе була. Нәкъ шул елларда ул татар энциклопедиясен булдыру идеясен тәкъдим итә. Ул Татарстанда яши торган татар һәм башка халыкларның хәзерге вакытта һәм үткәндә булган җәмәгать эшлеклеләре турында төрле биографик мәгълүматлар туплый башлый. Татарэнциклопедиясен булдыру турындагы карар Р.Таһировның үлеменнән соң кабул ителә. 1997 елда Таһировлар гаиләсе Татар энциклопедиясе институтына 22 папкада тупланган мәгълүмат тапшыра.

1930 елда Р.Таһиров педагогика институтына укытучылык эшенә чакырыла. Монда ул гомеренең актык көннәренә кадәр эшли, ассистенттан – профессор, тарих факультеты деканы дәрәҗәсенә кадәр үсә. 1930 еллар уртасыннан аның фәнни эшчәнлеге заманы өчен актуаль тема булган I Интернационал тарихына багышлана. Кандидатлык диссертациясен язып бетерә алмый – сугыш башлана. Р.Таһиров Иделдән алып Берлинга кадәрге сугыш юлын үтә, 1945 елның апрелендә Берлин тирәсендә ул каты яраланып, октябрьгә кадәр госпитальдә дәвалана.

Сугыштан соң ул катлаулы һәм бик җаваплы фән – Европа һәм Америка илләренең иң яңа тарихын укыта башлый. 1949 елда кандидатлык диссертациясен тәмамлагач һәм аны Мәскәүдә уңышлы гына яклагач, алдагы елларда ул I Интернационал тарихы һәм историографиясен өйрәнүен актив рәвештә дәвам итә, мәкаләләр бастыра, конференцияләрдә катнаша һәм лаеклы рәвештә әлеге мәсьәлә буенча танылган белгеч була. 1968 елда аның «Беренче Интернационалның рус һәм совет историографиясе. Беренче бүлек» монографиясе дөнья күрә, ул докторлык диссертациясенең бер өлеше итеп планлаштырылган була.

Профессор Таһиров күпләргә педагог-методист, урта мәктәпләрдә тарих укыту методикасы буенча мәкаләләр авторы буларак таныш. Татар теле, әдәбияты һәм тарихы бүлегендә берничә ел буе «Хәзерге татар әдәбиятында чит илдә булган күренешләрнең чагылышы» темасына махсус семинарлар үткәрде. Ул татар язучыларының әсәрләрен яхшы белә, аларның күбесе белән шәхсән таныш та иде.

Күпсанлы студентлары һәм хезмәттәшләре Р.Таһировны югары квалификацияле, таләпчән педагог, гадел һәм принципиаль шәхес, патриот буларак истә саклыйлар. Хәрби бүләкләрдән тыш, аның хезмәте «Трудовое Красное Знамя» ордены, «Отличник народного просвещения» билгесе һәм башка мактау билгеләре белән бәяләнде.

Яшьлек–яңарыш

Казан федераль университетында «Студентларның хезмәт отрядлары» оешмасы эшләп килә. Университет җитәкчелеге ярдәме белән 2011 елның февраль аенда гына эшчәнлеген яңадан башлап җибәргән штабның әйбәт кенә нәтиҗәләре бар. Оешма, яңа составта бик яшь булса да, аның тарихы шактый еракка китә. XX гасырның икенче яртысында уку йортында хезмәт отрядлары бик актив эшли. Бүгенге оешма турында тулырак мәгълүмат алу өчен, аның рәисе Гадел Зелаевка мөрәҗәгать иттек.

# «Эшче» студентлар өчен

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

**Студентларны уку йортындагы төрле оешмалар кызыксындыра. Сез оешмага нинди таләпләр нигезендә кабул итәсез?**

Хәзерге вакытта безгә бик күп яңа активистлар омтыла. Алар арасында төрле курсларда белем алучы студентлар бар. Кайберләренең беренче курстан ук киләчәк турында уйланулары бик сөендерә. Ләкин иң яхшылар рәтенә керү өчен, үзеңне бар яктан да күрсәтеп, отрядлар үткәргән чараларда актив катнашырга кирәк. Шул очракта безнең оешмага керергә мөмкин.

**Сезнең студентлар нинди эшләр башкара?**

Без студентларга университет, республика, Россия күләмендә үзләренең сәләтләрен күрсәтү өчен, барлык мөмкинлекләр дә тудырабыз. Безнең алдынгы яшьләр ел саен төрле студентлар мәктәпләренә баралар. Менә октябрь ахырында безнең оешмадан 2 студент Сочига, Бөтенрәсәй слетына бара.

**Студентлар белән нинди чаралар үткәрәсез?**

Безнең коллектив бик дус, бер-беребез белән һәрвакыт элемтәдә торабыз, бергәләп ял итәбез. Оешмага керү – ул яңа дуслар табу, аралашу дигән сүз! Без атна саен җыелышлар, өйрәтү дәресләре үткәрәбез, бергәләп киногa барабыз, табигатькә чыгабыз.

**Уку белән эшне бергә алып бару проблемалар китереп чыгармыймы икән?**

Бездә хезмәт урыннары бик күп, һәр студент белән килешеп, аларга туры килә торган вариантларны сайлыйбыз. Әлбәттә, укуга бернинди зарар да килергә тиеш түгел, шуңа күрә каядыр китеп эшләүләр җәй көне генә башкарыла.



**Киләчәккә нинди планнар төзисез?**

План-максатлар күп инде. Безгә Универсиада авылында аерым эш бүлмәсе бирергә тиешләр, шуны көтәбез. «Ел студенты» конкурсында «Студентларның иң яхшы хезмәт отряды» дигән исем яуларга уйлыйбыз. Бераз алга китеп әйткәндә, җәй көне без ике меңнән артык студентны эшкә урнаштырырга дигән максат куйдык.

Максатларыгызга ирешергә язсын. Хәзерге студентларның бик сирәге генә эшләмичә укый. Нишлисең бит, заман таләбе... Әгәр уку белән бергә алып барырдай эш табарга телисез икән, оешмага рәхим итегез. Алар бик теләп ярдәм итәчәкләр.

Ана теле




# «Бу - прикольно!»

Мин кем? Мин-татар! Әти-әнием татар! Татарстанда яшим! Татар булуым белән горурланам! Татарча сөйләшәм! Татар телен Яратам!!!

**Гөлия ИМАМОВА,**
Филология һәм сәнгать институты

Әнишләп соң минем яшьтәшләрем, төрле шәһәрләрдә яшәүче дусларым, татар телендә сөйләшмиләр? Үзләренең ана телен белмиләр? Аның белән кызыксынмыйлар? Җитмәсә, әти-әниләре чиста татар кешеләре, ә балалары рус телендә сөйләшә. Нишләп? Мин шуны аңламыйм?!

Нигә син рус телендә сөйләшәсең? Бу сорауны мин, кайсы гына дустыма әйтсәм дә, җавап бер үк: «Бу – прикольно!» – диләр. Нәрсәсе «прикольно» моның? Татар булып, рус телендә сөйләшүме? Ата-баба телен бозумы? Татар телендә бер сүз әйтә белмәүме? Милләтеңә төкереп бирүме? Бу - прикольномы?

Әлбәттә, мондый күренешне шәһәрдә генә түгел, хәтта авылларда да күреп була. Авылда хәлләр бигрәк тирәнгә киткән. Монда татар теле белән рус телен кушып сөйләшү «модада». Мисалга ике кызның сөйләшүе:

– Син бит миңа обещать иткән идең, новый күлмәгеңне күрсәтергә?

– Нуу, забыла бит, дустым! Завтра киеп килермен!

Шул ук җөмләләрне чиста татар телендә әйтсәң, матуррак яңгырар һәм нәрсә турында сүз барганы аңлашылыр иде.

Ә менә калган милләт яшьләре татар теленә бер дә битараф түгел. Киресенчә, безнең тел аларга ошый. Татар телендә сөйләшергә тырышалар, моңлы итеп җырлыйлар, татарларның гореф-гадәтләрен өйрәнәләр. Кызыксынып, яратып, татар теленә уңай мөнәсәбәтләрен белдерәләр.

Ә без, татар балалары, моны күрмибез, аңламыйбыз, ишетмибез. Әй татар, йоклама, уян! Без – бер бөтен, бүленмәс милләт! Шуның белән горурланып, баш күтәреп йөрик! Саф ана телендә сөйләшү, милләтеңне ярату, аның белән горурланып яшәү – менә бу прикольно!!!

**Әдәби сәйләннәр**



*«Исәнмесез, хөрмәтле «Дарелфөнүн» газетасы редакциясе хезмәткәрләре. Сезгә Эльвина Лотфуллина яза. Мин тумышым белән Азнакайдан: анда тудым, үстем, беренче сыйныфка укырга кердем. 7 классны тәмамлаганнан соң, 14 яшемдә әти-әниләремнән аерылып, еракка – Казанга укырга килдем һәм бүгенге көндә мин «Н.И.Лобачевский исемендәге лицей» КФУның гомуми белем бирү мәктәп-интернатының 8 Б сыйныф укучысы. Туган ягымнан ерак булсам да, иҗләштем, миңа монда ошый, ләкин хыялым – Санкт-Петербургта яшәү. Буш вакытларымда дусларым белән очрашырга, гитарада уйнарга, иҗат белән шөгыльләнергә яратам. Сезнең газетаны да укып барырга тырышам. Укучылар игътибарына иҗатымның бер өлешен тәкъдим итәсем килә».*

# Бәхетле көн...

Иң бәхетле көн... Әгәр миңа бу сорауны ике ай элек биргән булсалар, мин, әлбәттә, я туган көнем, яисә яңа ел, сабантуй бәйрәмнәре дип әйтер идем. Ә хәзер барысы да үзгәрде... Юк, бары да үз урынында – мин үзгәрдем. Ничек итеп, ник алай дип сорарсыз. Минем моңарчы гадәти булган әйберләргә карашым үзгәрде.

Хәзер минем өчен иң бәхетле көн – ялларда өйгә: якыннарым, туганнарым, дусларым янына кайту. Менә ул чын бәхет икән, дусларым! «Кем аерылмый, шулар белми аерылу сагышларын», – дип җырлыйлар. Мин дә моның дөреслеккә туры килүенә инандым. Юкка гына бөек шәхесләр шигырьләрендә, җырларында, көй-моңнарында туган якны, туган җирне, өйне, якын кешеләрен сагынулары турында сөйләмиләр икән. Өйдән ерак киткәч кенә, әти-әнинең, туганнарның кадерен белә башлыйсың. Шуңа күрә хәзер минем иң бәхетле мизгелем – туган якларыма кайту, газиз кешеләрем белән күрешү. Туган ягымдагы һава да икенче төрле кебек тоела миңа. Элек игътибар ителмәгән төрле вак-төякләр дә күзгә күренә хәзер: безнең өй алдында үсеп утырган ак каен башка җирдә үсә торган каеннарга караганда матуррак! Бәлки, кемгәдер бу бик көлке тоелыр, ләкин бу халәт туганнарыңнан аерылгач кына барлыкка килә икән шул. Бәлки, элек мин дә мондый хисләре булган кешене аңлап бетермәгәнмендер...

Халык: «Булмас димә – дөнья бу», – ди. Хак сүз икән. Шулай итеп минем өчен бәхетле көннәрем елга бер түгел, ә атна саен диярлек кабатлана. Өйгә кайту юллары гына өзелмәсен һәм өйдә һәрвакыт көтеп алучылар булсын!



**Сәяхәттән кайткач**



# Калабрия – контрастлар дөньясы

**Александра СТАРОЖИЛОВА,** Экология һәм география институты

Калабрия – Италиядәге искиткеч урын. Ул Апеннин ярымутравының көньяк өлешен биләп тора. Аны көнбатыштан Тиррен, көнчыгыштан – Ионик диңгезләре, төньяк-көнбатыштан – Таранто култыгы, ә көньяк-көнбатыштан Месинский бугазы юа.

Калабриягә беренче мәртәбә эләгүчеләр үзләрен монда кайчандыр булган, аның матур урыннарын күргән, борынгы, серле урамнары буенча йөргән кебек хис итә. Әмма шул ук вакытта көтелмәгән ачышлар булачагына да шик юк. Калабрия беренче мизгелләрдән үк үзенең җылылыгы һәм гадилеге белән каршы ала. Сәяхәтегез вакытында диңгез, борынгы замоклар күрергә, искиткеч тәмле ашлардан авыз итәргә теләсәгез, сезгә, һичшиксез, Калабриягә барып кайтырга кирәк! Урамнар буйлап йөргәндә, сез яңа пешкән круассан һәм кофе исләрен тоячаксыз. Нәкъ менә Италиядә чып-чын паста, пицца һәм күренекле «Тартюфо» туңдырмасын ашап карарга мөмкин. Сүз уңаеннан, пицца да Калабриядә барлыкка килгән.

Моннан тыш, Калабриядә истәлекле урыннар да шактый. Ерак түгел кечкенә шәһәрчекләр урнашкан. Аларның һәрберсе үзенә генә хас мәдәният һәм тарихка ия. Әйтик, сез монда Сан-Никола-ин-Платеис чиркәве, Сан-Леолук соборы, XIII – XV гасырның Арагон замогы, IX гасырның кафедраль замогы һәм башкалар белән таныша аласыз. Вулкан өстендә тормыш итүне беркемгә дә теләмәс идем. Ләкин, куркыныч булуга карамастан, кешеләр элек-электән вулкан урнашкан тау битендә яшәргә омтылган. Этна вулканындагы тормышның хәзерге халәтен күрү өчен, автомобиль белән бер көнлек экскурсия дә җитә. Калабриялеләр бик күңелле халык, атна саен алар нәрсәгә дә булса багышланган бәйрәмнәр оештыралар: суган, борыч, шәраб бәйрәме, уйлап чыгарылган каһарманнар бәйрәме һ.б.

Сәяхәтем өч ай буе дәвам итсә дә, үземә өч көн генә булып тоелды. Вакыт сизелмичә узды да китте. Төп сәбәп: Калабриялеләр туристлар өчен бөтен шартларны да тудырганнар. Мин үземне күп вакыт өйдәге кебек хис иттем.

**Мәсьәләгә бер караш**

# Стипендия җитәме?

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

ЕШ КЫНА ӨЛКӘН КЕШЕЛӘРДӘН, БЕЗ УКЫГАН ЗАМАНДА, СТИПЕНДИЯ АКЧАСЫНА БЕР АЙ БУЕ РӘХӘТЛӘНЕП ЯШӘП БУЛА ИДЕ, ДИГӘН СҮЗЛӘР ИШЕТЕРГӘ БУЛА. ШУНЫСЫ КЫЗЫК: ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫМЫ, УЧИЛИЩЕМЫ - СТИПЕНДИЯ КҮЛӘМЕ БАРЫБЕР ҖИТКӘН. Ә БҮГЕНГЕ СТУДЕНТЛАРНЫҢ СТИПЕНДИЯСЕ НӘРСӘГӘ ҖИТӘ ИКӘН СОҢ?

### Стипендиянең дә була төрлесе

Бер республикада укысак та, башкаланың төрле вузларында белем алучы студентлар төрле стипендия ала икән. Иң «байлар» хәрбиләр әзерли торган вузларда укый. Булачак полиция хезмәткәрләренең стипендиясе – 12 мең, әмма, бишенче курска җиткәч, студент 20 меңгә якын алачак. Шуны онытмыйк: дәүләт бу вузларда белем алучыларга форма һәм бушлай ашау мөмкинлеген дә бирә.

«Гражданский» вузларда исә хәлләр бераз мөшкел. Мәсәлән, гадәти стипендия уртача – 1300 сум, югарысы – 1800 сум. Югары стипендиянең күләмен, күбесенчә, һәр факультет үзе билгели, ул якынча 3-8 мең сумны тәшкил итә.

### Студент «Шабашка»сы

Сәләтле, тырыш студент булсаң, стипендиядән тыш, бераз «шабашка» да эшләп була. Гадәттә, югары уку йортларында актив студентлар өчен махсус программа каралган. Университет тормышында кайнаган, вуз өчен төрле бәйгеләрдә катнашкан егет-кызларга, стипендиягә өстәп, акча түлиләр.

Тик, мин бии дә белмим, «КВН»щик та түгел, дип аптырама. Югары уку йортларында «акыллылар» да акчасыз калмый. Чөнки вузда грант дип аталган күп кенә бәйгеләр уза. Төрле докладлар әзерләргә, фәнни эшләр язарга яратасың, әле моңа өстәп күп кенә китаплар да укыйсың икән, бәлки, озакламый син дә грант иясе булырсың. Анысы инде үзеңнән тора. Тик шунысы кызганыч: гадәттә, грантлар турында студентлар белми кала. Ә бит мондый бәйгеләр ел саен уздырыла.

### Кызыклы арифметика

Казан студентларының стипендия күләме турында әйтеп киттек. Әмма язма башында куелган сорауга җавап әле бирелмәде. Шуңа күрә мисал өстендә сөйләшеп карыйк. Әйтик, Айгөл исемле кыз Казан федераль университетында укый. Аңа әти-әнисенең булышыр мөмкинлеге юк. Әмма бу студент яхшы укый, шуңа күрә калганнарга караганда югарырак стипендия ала (1800 сум чамасы). Моңа өстәп, аның кулына ай саен тагын 1800 сум акча кереп бара, анысы инде – социаль стипендия. Исәпләп карыйк әле, бәлки, бу акчага да бер ай яшәп буладыр?

Әлбәттә, беренчедән, торак мәсьәләсен карарга кирәк. Сүз юк, бары тик стипендиягә генә яшәүче студентка, фатир яки бүлмәне арендага алу турында хыялланасы да юк. Шуңа күрә бу очракта булачак белгечкә тулай торакта яшәргә туры килә. Аның өчен аена 80 сумга якын түлисе булачак. Йокларга урыны булды, ди. Икенче мәсьәлә: университетка һәм башка кирәк булган җиргә ничек барып җитәргә? Тулай торак университет янында урнашкан булса, бик яхшы, тик Казанда андый вузлар саны санаулы. Димәк, студентка җәмәгать транспортыннан файдаланырга кирәк булачак. Белгәнебезчә, автобуста 19 сум калдырасы була. Әле кайтырга да кирәк – 38 сум. Димәк, юл студент кесәсен тагын да юкарта. Элек, троллейбусларда йөрер өчен, студентлар өчен махсус «проездной» сатыла иде. Хәзер анысын да бетерделәр.

Студент автобуста йөрсә, тулай торакта торса, аның бер ай яшәү өчен якынча 2500 сум акчасы калачак. Димәк, стипендияне бер айга җиткерү өчен, көнгә, күп дигәндә, 83 сум тотарга мөмкин булачак. Хәзерге заманда бу акчага нәрсә алып була? Кефир белән ипи һәм ВУЗ ашханәсендә чәй? Кызлар өчен бу менә дигән «диета», ләкин егетләр риза булмас.

Ә бит студент уку белән генә шөгыльләнми. Аның ял итәсе дә килә. Башкалар йөргән кино, боулинг, дискәтүкләр дә студент халкын кызыктыра. Нәтиҗә бер: гадәти вузда укучы студент бары тик стипендия акчасына гына бер ай яши алмаячак. Шуңа күрә инде студентлар, күбесенчә, әти-әни җибәргән акчаны көтәләр. Әлбәттә, «оятлары» булган егет-кызлар үзләре дә акча эшләргә тырыша. Әмма көндезге бүлектә укучыларга, тыгыз уку графигы белән бергә, берәр эштә дә эшләү мөмкинлеге эләкми бит.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.